**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода, ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе, Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.10.2015 Балык бистәсе штп. № 293пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзелешкә контрольне гамәлгә ашыруга "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының капиталь төзелеш һәм ремонт буенча бердәм заказчы хезмәте» муниципаль унитар предприятиесенең чыгымнар нормативы турында

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының капиталь төзелеш һәм ремонт буенча бердәм заказчы хезмәте» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан гамәлгә ашырыла торган төзелеш контроле хезмәтләре өчен түләүгә чыгымнарны аныклауның бердәм тәртибен билгеләү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда һәм капиталь ремонтлаганда төзелеш контролен үткәрү тәртибе турында» 2010 елның 21 июнендәге 468 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1."Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Капиталь төзелеш һәм ремонт буенча бердәм заказчы хезмәте» муниципаль унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан финанслау чыганакларына карамастан, капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең һәм капиталь ремонтның гомуми бәясеннән чыгып, төзелеш контролен тормышка ашыру чыгымнары нормативын, җир сатып алу чыгымнарыннан тыш, 1,09% күләмендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 21 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда һәм капиталь ремонтлаганда төзелеш контроле үткәрү турындагы Нигезләмә нигезендә җир кишәрлекләрен сатып алуга чыгымнардан тыш, билгеләргә тәкъдим итәргә.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Д. А. Низамовка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р. Х. Хәбибуллин